СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

31.03.2026 № 8/12

На №__________от______________

# КАРАР

## 2026 елга Тукай муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру фараз планын (программасын) раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законга, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законга, Советның 2018 елның 10 декабрендәге 29/9 номерлы карары белән расланган «Тукай муниципаль районының муниципаль мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү тәртибе турында» нигезләмәгә, Тукай муниципаль районы уставына таянып, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2026 елга «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру фараз планын (программасын) әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары,
Совет Рәисе урынбасары Р.И.Закиров

Тукай муниципаль районы Советының 2026 елның «30» мартындагы 8/12 номерлы карарына кушымта

2026 елга Тукай муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру фараз планы (программасы)

1. Гомуми нигезләмәләр

2025 елга Тукай муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру фараз планы (программасы) (алга таба – фараз планы) «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» Федераль закон, Советның 2018 елның 10 декабрендәге 29/9 номерлы карары белән расланган «Тукай муниципаль районы муниципаль мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү тәртибе турында» нигезләмә, Тукай муниципаль районы уставы нигезендә эшләнгән.

2026 елда хосусыйлаштыру планлаштырылган муниципаль мөлкәт объектлары исемлегенә районның муниципаль милкендәге объектлар кертелгән.

2026 елга Тукай районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру фараз планында (программасында) күрсәтелгән мөлкәт объектларын хосусыйлаштыру район икътисадында, шул исәптән икътисадның конкрет тармакларында (идарә өлкәләрендә) структур үзгәрешләргә йогынты ясамаячак.

Хосусыйлаштыру фараз планы гамәлдә булган вакытта 2026 елда хосусыйлаштыру планлаштырылган муниципаль мөлкәт исемлегенә Тукай муниципаль районы Советы карарлары нигезендә яңа күчемсез мөлкәт объектлары өстәлергә мөмкин.

2. Хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль мөлкәт

2.1. 2026 елда хосусыйлаштыру планлаштырылган муниципаль күчемсез мөлкәт исемлеге:

| Күчемсез милек объекты исеме | Урнашу урыны (адрес) | Гомуми мәйданы (кв. метр) | Планлаштырылган гамәлгә ашыру срогы/ гамәлгә ашыру ысулы |
|---|---|---|---|
| 16:39:170501:493 кадастр номерлы торак булмаган бина (элеккеге балалар бакчасы бинасы) | Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Иске Абдул авыл җирлеге, Иске Абдул авылы | 129,9 | 2026 ел, *аукционда сату юлы белән, гавами тәкъдим ярдәмендә сату, бәясен игълан итмичә сату |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | |

2.2. 2026 елда хосусыйлаштыру планлаштырылган муниципаль күчемле мөлкәт исемлеге:

| № | Объект (мөлкәт) исеме | Планлаштырылган гамәлгә ашыру срогы/ гамәлгә ашыру ысулы |
|---|---|---|
| 1 | Ford Mondeo, 2017 елда чыгарылган (VIN) Z6FDXXEECDHU27403, ПТС 16 OP551001 | 2026 ел, *аукционда сату юлы белән, гавами тәкъдим ярдәмендә сату, бәясен игълан итмичә сату |
| 2 | Ford Mondeo, 2013 елда чыгарылган, (VIN) X9FDXXEEBDDB24443, ПТС 47HO979527 | 2026 ел, *аукционда сату юлы белән, гавами тәкъдим ярдәмендә сату, бәясен игълан итмичә сату |
| 3 | Ford Explorer, 2017 елда чыгарылган, Z6FBXXESWBHR67180, ПТС 16 OC 308690 | 2026 ел, *аукционда сату юлы белән, гавами тәкъдим ярдәмендә сату, бәясен игълан итмичә сату |
| 4 | Mitsubishi ASX 1.6 Invite MT, 2011 елда чыгарылган, идентификация номеры (VIN) JMBXNGA1WCZ000123 | 2026 ел, *аукционда сату юлы белән, гавами тәкъдим ярдәмендә сату, бәясен игълан итмичә сату |
| 5 | Peugeot boxer 222335, 2013 елда чыгарылган, (VIN) XB9222335D0FD1603, ПТС 16HP885334 | 2026 ел, *аукционда сату юлы белән, гавами тәкъдим ярдәмендә сату, бәясен игълан итмичә сату |
| 6 | FIAT DUKATO, 2009 елда чыгарылган, (VIN)Z7G244000AS011896, ПТС 16MT177328 | 2026 ел, *аукционда сату юлы белән, гавами тәкъдим ярдәмендә сату, бәясен игълан итмичә сату |
| 7 | FIAT DUKATO, 2009 елда чыгарылган, (VIN) Z7G244000AS011932, ПТС16MT177340 | 2026 ел, *аукционда сату юлы белән, гавами тәкъдим ярдәмендә сату, бәясен игълан итмичә сату |

*Сатуның һәр чираттагы ысулы алдагы ысул булмаганнан соң тормышка ашырыла, сатулар электрон формада үткәрелә.